**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**БОЕРЫК**

17.11.2015 Казан шәһәре № 723

**Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 24 октябрендә чыгарылган 793 номерлы «Социаль хезмәтләр күрсәтә торган учреждениеләрнең эш сыйфатын бәяләүнең бәйсез системасын формалаштыру турында» карары нигезендә

**б о е р а м:**

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы каршында иҗтимагый совет төзергә (алга таба – Иҗтимагый совет).

2. Расларга:

- Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне;
- Иҗтимагый советның составын расларга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне министр урынбасары А.М.Миңгуловка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт
министрлыгының
17.11.2015 723 №лы
боерыгы тарафыннан
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында**
**нигезләмә**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1.Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет (алга таба – Иҗтимагый совет) эшчәнлегенең максатларын, бурычларын һәм оешманың нигезләрен билгели.

Иҗтимагый совет Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) каршындагы киңәш хокукы булган орган булып тора, ул Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте, физик тәрбия һәм спорт өлкәләрендә Татарстан Республикасында дәүләт сәясәтен формалаштырганда һәм тормышка ашырганда гражданнарның ireген һәм иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган оешмаларның хокукларын тормышка ашыру белән бәйле мәсьәләләрне карый, шулай ук әлеге нигезләмә тарафыннан билгеләнгән башка вәкаләтләрне тормышка ашыра.

1.2. Иҗтимагый советның составы һәм саны Министрлык боерыгы белән раслана.

1.3. Иҗтимагый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституцион законнар, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты боерыклары һәм күрсәтмәләре, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты боерыклары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре, шулай ук әлеге нигезләмәгә таянып эшли.

1.4. Иҗтимагый совет карарлары тәкъдим итү характерында була.

1.5. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген иҗтимагый башлангыч белән тормышка ашыра.

1.6. Иҗтимагый совет эше ирекле рәвештә, ачык һәм партнерлык принципларында һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына катгый туры китереп төзелә.

1.7. Иҗтимагый Совет үз эшен гражданлык җәмгыяте институтлары вәкилләренең, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының, массакүләм мәгълүмат чараларының үзара кызыксынучанлыгы нигезендә башкара.

## 2. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТНЫҢ МАКСАТЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ ВӘКАЛӘТЛӘРЕ

2.1.Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

- Гражданнарның ихтыяҗларын һәм кызыксынуларын исәпкә алу, гражданнарның хокук һәм ирекләрен һәм иҗтимагый берләшмәләр һәм башка дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган оешмаларның хокукларын саклау;
- Иҗтимагый, һөнәри һәм иҗади берләшмәләр вәкилләрен Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте, физик тәрбия һәм спорт өлкәләренә кагыла торган мәсьәләләр буенча дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләүгә тарту, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы эшчәнлегенең ачыклылык һәм хәбәрдарлык принцибын тормышка ашыру;
- Татарстан Республикасында дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре

сыйфатына карата җәмәгать контролен көчәйтү, аңа туры килә торган өлкәдә ачыклылык, законлылык һәм профессиональлек принципларын үстерү.

2.2. Иҗтимагый советның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте, физик тәрбия һәм спорт өлкәләрендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;
- Министрлык эшчәнлеге мәсьәләләренә кагыла торган норматив хокукый актлар проектларына җәмәгать экспертизасы үткәрү, шул исәптән министрлык эшли торган дәүләт программалары проектларын тикшерү;
- министрлык тарафыннан карарлар кабул иткәндә җәмәгать фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;
- министрлык эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекнең мәгълүматлылыгын арттыру;
- яшьләр сәясәте, физик тәрбия һәм спорт өлкәләрендә оешмалар тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәяләү уздыру.

2.3. Иҗтимагый советның максатлары һәм бурычлары аның эш нәтиҗәләренә бәйле рәвештә, шулай ук Россия Федерациясендә икътисадый, социаль һәм сәяси хәлләрне исәпкә алып, үзгәрергә һәм тулыландырылырга мөмкин.

2.4. Иҗтимагый совет яшьләр сәясәте, физик тәрбия һәм спорт оешмалары тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәяләү үткәрүне тормышка ашыру өчен аңарга йөкләнгән бурычлар чикләрендә:

- бәйсез бәя үткәрелә торган оешмаларның исемлеген ачыклый;
- яшьләр сәясәте, физик тәрбия һәм спорт оешмалары өлкәләрендә оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфаты турында мәгълүмат җыя, йомгаклый һәм анализлый торган оешмаларга техник биремнәр эшләү өчен тәкъдимнәр формалаштыра (алга таба – оператор), эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында документация проектларын, шулай ук Министрлык оператор белән төзи торган дәүләт контрактлары проектларын тикшерүдә катнаша;
- оешмалар күрсәтә торган хезмәтләр сыйфатына бәя критерийларын билгели, алар түбәндәгеләрне характерлый:
  - оешма турындагы мәгълүматның ачык һәм аңлаешлы булуын;
  - социаль хезмәтнең исемлеген, күләмен (дәүләт, муниципаль бурычта чагыла торган күрсәткечләр чигендә) һәм характеристикасын, аны күрсәтү технологиясен (медицина ярдәменнән тыш);
  - социаль хезмәтнең матди-техник һәм кадрлар белән тәэмин ителешен;
  - социаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен;
  - шартларның, шул исәптән сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән гражданнар өчен дә уңайлы булуы һәм хезмәт алуның мөмкин булуын;
  - хезмәт алганда чиратта көтү вакытын;
  - оешма хезмәткәрләренең башкаларга карата яхшы мөнәсәбәтен, әдәплелеген һәм хәбәрдар булуын;
  - оешмада хезмәт күрсәтүнең сыйфаты белән канәгать булган хезмәт алучылар өлешен;
- җәмәгать фикерен ачыклау, гомумиләштерү һәм анализлау һәм социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларның, шул исәптән социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар, һөнәри берләшмәләр һәм башка экспертлар тарафыннан формалаштырылган оешмаларның рейтингын төзү буенча эш оештыра;
- Министрлыкка түбәндәгеләрне җибәрә:
  - яшьләр сәясәте, физик тәрбия һәм спорт өлкәләрендә оешмалар күрсәтә торган хезмәтләрнең сыйфатына бәя нәтиҗәләре турында Иҗтимагый совет компетенцияләре кысаларында алынган мәгълүматны;
  - оешмаларның эш сыйфатын яхшырту, шулай ук хезмәт алу буенча мөрәҗәгать иткән затлар өчен кирәкле мәгълүматларны файдалана алуны оештыру турында тәкъдимнәрне.

## 3. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТНЫҢ СОСТАВЫ

3.1. Иҗтимагый совет рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм гражданнар, иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган оешмалар тәкъдиме нигезендә Иҗтимагый совет әгъзалары составында төзелә.

Иҗтимагый советның персональ составы Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры тарафыннан раслана.

3.2. Иҗтимагый совет ирекле катнашу нигезендә 12 кеше составында формалаштырыла.

3.3. Иҗтимагый совет составына шулай ук иҗтимагый оешмалар һәм башка социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләре дә керә ала.

Шуның белән бергә аларның профессиональ сыйфатлары, шул исәптән Иҗтимагый совет алдына куелган мәсьәләләрне тикшерү өчен кирәк булган белеме, әлеге өлкәдәге эш тәҗрибәсе исәпкә алына.

Иҗтимагый совет составына, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән затлар белән беррәттән Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан тәкъдим ителгән Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми күләменең яртысын тәшкил иткән кадәр санда затлар да кертелә.

Иҗтимагый совет составына Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының биштән береннән артып китмәгән санда элек Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләт гражданнар хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларында дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларында дәүләт гражданнар хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкарган затлар керергә мөмкин.

3.4. Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләт гражданнар хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларында дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларында дәүләт гражданнар хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкарган затлар, суд карары нигезендә эшкә сәләтсез дип табылган затлар, суд хөкемен капламаган яки алынмаган затлар, шулай ук 2005 елның 4 апрелендә кабул ителгән «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатаасы турында» 32-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары була алмаган башка затлар Иҗтимагый совет әгъзалары була алмый.

3.5. Иҗтимагый совет рәисе һәм рәис урынбасары Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан Иҗтимагый советның беренче утырышында ачык тавыш бирү юлы белән, Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының яртысы алар өчен тавыш биргән очракта, сайлана. Иҗтимагый совет рәисе һәм рәис урынбасарын сайлау турында карар Иҗтимагый советның рәисен һәм рәис урынбасарын сайлау турында карар Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет рәисен һәм рәис урынбасарын вазыйфасыннан азат итү мәсьәләсе Иҗтимагый совет тарафыннан Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры мөрәҗәгате, шулай ук аларның әлеге затларның шәхси гаризасы яки Иҗтимагый совет әгъзалары санының биштән бер өлеше тәкъдиме буенча карала.

Иҗтимагый совет әгъзаларының яртысыннан артыгы риза дип тавыш биргән очракта, карар кабул ителгән дип санала.

3.6. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләте түбәндәге очракларда тәмамлана:

аның тарафыннан Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза бирелсә;

сәламәтлегенә бәйле рәвештә Иҗтимагый совет эшендә катнашу мөмкинлеге чикләнсә, үзе Иҗтимагый совет эшчәнлегеннән читләшкән очракта яки башка сәбәпләр буенча;

аңа карата чыгарылган хөкем карары законлы рәвештә үз көченә кергәч;

закон буенча үз көченә кергән хөкем карары нигезендә эшкә сәләтсез яки хәбәрсез югалган дип табылгач;

әхлак нормаларын тупас рәвештә бозаган өчен – Иҗтимагый советның утырышта булган әгъзаларының гомуми санына карата күпчелек тавыш белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;
Россия Федерациясе гражданы булудан туктаганда;
систематик рәвештә (өч мәртәбәдән артык) нигезле сәбәптән башка Иҗтимагый совет утырышы эшендә катнашмагач;
систематик рәвештә (ике мәртәбәдән артык) нигезле сәбәптән башка Иҗтимагый совет рәисе яки рәиснең урынбасары йөкләмәсен башкармау;
аны Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләт гражданнар хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларында дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларында дәүләт гражданнар хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларына билгеләү;
аның тарафыннан икеләтә гражданлык алу.

3.7. Иҗтимагый советта әгъза булуны туктату Иҗтимагый совет әгъзасының язмача гаризасы яисә Иҗтимагый совет рәисе яисә рәис урынбасары күрсәтмәсе нигезендә кабул ителгән, шулай ук әлеге нигезләмәнең 3.6. пунктында каралган шартлар ачыкланган очракларда Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры карары белән яраклаштырылып тормышка ашырыла.

Иҗтимагый совет әгъзасының сәламәтлек буенча, аңа карата судның гаепләү карары закон көченә кергәндә, Россия Федерациясе гражданы булудан туктаган очракларда эшчәнлеген тормышка ашыру сәләте беткән очракларда Иҗтимагый совет әгъзасы әлеге фактлар турында Иҗтимагый совет рәисенә яки рәис урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре Иҗтимагый совет рәисе күрсәтмәсе буенча яшьләр эшләре һәм спорт министры карары белән бәйле рәвештә түбәндәге очракларда туктатыла:
аңа карата Россия Федерациясе процессуаль законнары тарафыннан куелган тәртиптә җинаять кылуда гаепләнгәндә;
аңа административ арест формасында административ җәза билгеләнгәндә;
аны дәүләт хакимиятенең закон чыгару (сайлап куела торган) органына депутатлыкка кандидат, җирле үзидарә органында сайлана торган вазыйфага кандидат, сәяси партия кандидатының ышанычлы вәкиле яки вәкаләтле заты итеп теркәү, шулай ук Россия Федерациясендә референдум уздыру буенча инициативалы группа составына кергән очракта.

## 4. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ӘГЪЗАЛАРЫНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

4.1. Иҗтимагый совет әгъзасының хокуклары түбәндәгечә:
башкарма комитет инициативасы буенча уздырыла торган барлык чараларда (утырышлар, киңәшмәләр, «түгәрәк өстәлләрдә» һ.б.) катнашырга, федераль законнар белән тыела торган дәүләт сере, шәхси мәгълүматлар һәм чикләнелгән рөхсәте булган мәгълүматларны кулланып үткәрелә торган чаралардан тыш;
инициатива тәртибендә Иҗтимагый советка аналитик язмалар, чыгышлар һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар хәзерләргә һәм җибәрергә;
Иҗтимагый совет рәисе аша Иҗтимагый советның эш планына һәм аның утырышларын үткәрү тәртибенә тәкъдимнәр кертергә;
Көн тәртибендәге мәсьәләләрне карауда катнашу өчен Иҗтимагый совет утырышларына чакырыла торган затлар кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертергә;
Иҗтимагый совет әгъзалыгыннан чыгу.

4.2. Иҗтимагый совет әгъзасы тиеш:
Иҗтимагый совет рәисе тапшырган эшне үтәргә;
әлеге нигезләмәдә билгеләнгән Иҗтимагый советның эш тәртибен белергә һәм үтәргә;
Иҗтимагый совет утырышларында үзе катнашырга;
Куелган бурычларны чишү өчен Иҗтимагый совет төзегән эксперт, эшче группалар,

комиссияләр, башка эшче группалар эшендә катнашырга.

## 5. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТНЫҢ ЭШ ТӘРТИБЕ

5.1. Иҗтимагый совет үзенең эшен Иҗтимагый совет рәисе тәкъдим итүе буенча Иҗтимагый совет утырышында расланган планнар һәм программалар буенча оештыра.

5.2. Иҗтимагый совет эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзалары, Иҗтимагый совет рәисе һәм Министрлык тәкъдимнәре нигезендә тормышка ашырыла.

5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга бер тапкырдан да сирәгрәк уздырылмый. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук Министрлык инициативасы буенча Министрлык тарафыннан эшләп чыгарылган норматив хокукый актлар һәм башка документлар исемлегендә каралган Иҗтимагый совет утырышларында алдан тикшермичә торып кабул итү мөмкин булмаган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 мартында расланган «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләп чыгарыла торган башкарма хакимиятнең әлеге органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан тикшермичә кабул итү мөмкин булмаган норматив хокукый актлар һәм башка документлар составын раслау турында» 214 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан эшләп чыгарыла торган норматив хокукый актлары һәм башка документлар исемлегендә каралган норматив хокукый актлар проектларына һәм Министрлыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына билгеләнгән тәртиптә теркәүгә җибәрелә торган норматив хокукый актларына бәяләмә бирү максатында да уздырылырга мөмкин.

5.4. Иҗтимагый совет утырышлары андагы әгъзаларның өчтән ике өлешеннән артыгы катнашкан очракта тулы хокуклы дип санала. Иҗтимагый совет әгъзасының, утырышта үзенең катнашу мөмкинлеге булмаганда, моның турында алданрак Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасарына, яки җаваплы сәркатипкә хәбәр итеп, көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча тавышын һәм үз фикерен язмача, факсимиль яки электрон почта аша Иҗтимагый советның башка әгъзасына тапшырырга хокукы бар. Иҗтимагый совет утырышында катнашучылар санына үз тавышларын Иҗтимагый советның башка әгъзаларына тапшырган Иҗтимагый совет әгъзалары өстәлә.

Әлеге нигезләмәнең 5.3. пунктының икенче абзацында күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларын (норматив хокукый актлар) Иҗтимагый советта карау министрлык тарафыннан аны Иҗтимагый советка җибәрелгән көннән ун календарь көне эчендә башкарыла. Шуның өстенә алар буенча Иҗтимагый совет бәяләмәсе бирү максатларында тавыш бирү уздыру Иҗтимагый советның барлык әгъзалары арасында сораштыру формасында читтән торып та уздырылырга мөмкин, сораштыру нәтиҗәләре Иҗтимагый совет рәисе, ул булмаганда Иҗтимагый совет рәисе урынбасары тарафыннан имзалана торган беркетмәгә кертелә. Мондый тавыш бирү тапшырыла һәм кабул ителә торган хәбәрләрнең дөреслеген һәм аларның документлар белән расланауын тәэмин итә торган почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон һәм башка төр элемтә аша документлар алмашу юлы белән уздырылырга мөмкин. Читтән торып тавыш бирү үткәрелгән очракта рәис урынбасарына, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларына көн тәртибе, Иҗтимагый совет бәяләмәсе бирелә торган норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) аны үткәрү датасына кадәр җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрелә. Иҗтимагый совет әгъзалары, андый ихтыяҗ булганда, министрлыктан карала торган норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) буенча өстәмә материаллар һәм мәгълүмат сорыйлар һәм алалар.

Иҗтимагый совет карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

5.5. Иҗтимагый совет утырышларын Иҗтимагый совет рәисе, ә ул булмаганда – Иҗтимагый совет рәисе урынбасары уздыра.

5.6. Иҗтимагый совет аңа йөкләнгән максатлар, бурычлар, вәкаләтләргә туры китереп кабул ителә торган карарлары тәкъдим итү характерында була һәм кызыксынучы затларга Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсеннән өземтә формасында яисә Иҗтимагый совет карары буенча башка

юл белән җиткерелә.

5.7. Иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүмат Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә министрлык сайтында яисә «Иҗтимагый совет» күрсәтмә битендә урнаштырыла.

5.8. Иҗтимагый совет рәисе:

Иҗтимагый совет эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүне тормышка ашыра;

Иҗтимагый совет утырышларын алып бара;

Иҗтимагый совет әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый совет эш планнарын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм Иҗтимагый советта аларны раслауга тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет утырышларын оештыра;

Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен раслый;

Иҗтимагый совет тәкъдимнәренә, беркетмәләренә һәм Иҗтимагый советның башка документларына имза куя;

Иҗтимагый совет утырышларын үткәрү вакытын һәм урынын билгели;

Иҗтимагый совет эшчәнлеге, аңа салынган максатлар һәм бурычлар кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына эшләр (йөкләмәләр) бирә;

Иҗтимагый совет исеменнән сораулар, рекомендацияләр, тәкъдимнәр, җаваплар, аңлатмалар һәм мөрәҗәгатьләрне имзалый;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәк булган башка функцияләрне башкара.

5.9. Иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

Иҗтимагый совет рәисе булмаганда рәсми рәвештә аның функцияләрен башкара;

Иҗтимагый совет утырышына әзерләнүне оештыра;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзи һәм аны Иҗтимагый совет рәисенә расларга бирә;

Иҗтимагый совет рәисе кушуы буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен зарури булган башка функцияләрне башкара.

5.10. Иҗтимагый советның җаваплы сәркатибе:

утырышларга материаллар һәм карарлар проектларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет әгъзаларына Иҗтимагый советны уздыру вакыты һәм урыны, көн тәртибе турында мәгълүмат бирә, аларны кирәкле барлык мәгълүмати-белешмә материаллар белән тәэмин итә;

Иҗтимагый совет һәм башкарма комитетның оештыру буенча үзара тәэсир итешүен тәэмин итә;

Иҗтимагый совет эшчәнлегенең документаль-техник тәэмин ителешен тормышка ашыра;

Иҗтимагый совет утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшерүне тормышка ашыра;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзүдә катнаша.

5.11. Иҗтимагый совет әгъзалары, Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән килешеп, Иҗтимагый совет утырышларында тыңлау һәм җентекләп тикшерүгә мәсьәләләр әзерләү өчен эшче, эксперт группаларына һәм башка эшче группаларга берләшә, материаллар әзерләүгә Иҗтимагый совет составына керми торган белгечләрне тарта ала.

5.12. Иҗтимагый совет карары белән Иҗтимагый совет карый торган мәсьәләләр буенча кирәк булган мәгълүмат һәм бәяләмәләр бирү өчен Иҗтимагый совет утырышларына министрлык, коммерциячел булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре чакырылырга мөмкин. Иҗтимагый совет әгъзалары булмаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Иҗтимагый совет чакыруы буенча Иҗтимагый совет утырышларында катнаша ала.

5.13. Иҗтимагый совет каравына чыгарыла торган материаллар Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына алар тикшереләчәк дип билгеләнгән датага кадәр ун көннән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш. Материалларны соңрак тапшыру Иҗтимагый совет рәисе яисә рәис урынбасары белән килештерелә.

5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлеген техник һәм оештыру яктан Министрлык тәэмин итә.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы каршындагы
Иҗтимагый совет составы

| № | Ф.И.А. и. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Бәхтияров Тимур Александрович | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының мәгариф һәм фән мәсьәләләре буенча комиссиясе әгъзасы |
| 2. | Бикчәнтәева Ләлә Дмитриевна | Татарстан Республикасы Иҗтимагый советының мәгариф һәм фән мәсьәләләре буенча комиссиясе әгъзасы |
| 3. | Демина Светлана Александровна | Спорт ветераны, СССРның атказанган спорт мастеры, Олимпия уеннарының көмеш приз иясе, дөнья чемпионы |
| 4. | Заһидуллина Миләүшә Мөдәрис кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының социаль сәясәт мәсьәләләре буенча комиссиясе әгъзасы |
| 5. | Зиннуров Ирек Хәйдәр улы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый советының социаль сәясәт мәсьәләләре буенча комиссиясе әгъзасы |
| 6. | Капустин Денис Викторович | Атказанган спорт мастеры, Татарстан Республикасы җыелма командасының баш тренеры, Татарстан Республикасы җиңел атлетика федерациясе вице-президенты, җиңел атлетика буенча (өчле сикерү) 2000 елдагы Олимпия уеннарының бронза призы иясе |
| 7. | Павлова Ольга Ивановна | Россиянең атказанган тренеры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты |
| 8. | Сәфәрова Диана Әсхәт кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының мәдәният, этникара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча комиссиясе әгъзасы |
| 9. | Туманин Виктор Евгеньевич | Татарстан Республикасының Яшь галимнәре һәм белгечләре хәрәкәте башкарма комитеты рәисе |
| 10. | Халиков Тимур Рафаэль улы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасвның икътисадый үсеш мәсьәләләре буенча комиссиясе рәисе |
| 11. | Хаматов Айрат Касыйм улы | Атказанган спорт мастеры, бокс буенча дөнья чемпионы, Татарстан Республикасы бокс федерациясе президенты |
| 12. | Харисов Әмир Ринат улы | Татарстан Республикасы «Буревестник» яшьләр физик тәрбия-спорт җәмгыяте рәисе, «Россия студентлары спорт союзы» Бөтенроссия җәмәгать оешмасы башкарма комитеты әгъзасы |